ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кукмара муниципаль районы
Түбән Өскебаш авыл жирлеге Советы

# КАРАР

2020 елның 28 январе 1 номерлы

Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексынын 31 бүлеге нигезендә Түбән Өскебаш авыл җирлеге карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге Түбән Өскебаш авыл жирлеге Советының 26 номерлы карарына (Түбән Өскебаш авыл жирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 34 номерлы, 2015 елнын 27 маендагы 24 номерлы, 2015 елның 17 ноябрендәге 14 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 11 номерлы, 2018 елнын 29 ноябрендәге 31 номерлы, 2018 елның 17 декабрендәге 33 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 22 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кадастр хакының 0,1% ы – 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяжлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук Түбән Өскебаш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында да.

3. Әлеге карар29.02.2020 елда Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге башлыгы: Н.М.Мухаметзянов